ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноября 2024 ел № 302

«Әгерҗе муниципаль районында МБУ хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 168 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 07 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе муниципаль районында МБУ хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 168 номерлы карарына бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).
4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 01.11.2024 елның 302
номерлы карары белән расланды

**«Әгерҗе муниципаль районында МБУ хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 168 номерлы карарына үзгәрешләр**

1. Әгерҗе муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әгерҗе муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31500 |
| Бүлек башлыгы | 27700 |
| I категорияле Бухгалтер | 25300 |
| Бухгалтер | 24000 |
| Персонал буенча белгеч | 25300 |
| Система администраторы | 25300 |

».

2. Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары баш бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны 3,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары |
|---|---|
| Бухгалтер | 24000 |

».